# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Баулы районы һәм Баулы шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Баулы районы һәм Баулы шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 112-ТРЗ

«Татарстан Республикасы
Баулы районы һәм Баулы шәһәре буенча
Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Баулы районы һәм Баулы шәһәре буенча**
**Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының**
**суд участоклары чикләре**
**тасвирламасы**

## 1 нче суд участогы

1 нче суд участогы чигенә «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көнчыгыш чигендә Казан – Оренбург автомобиль юлы һәм Ваһапов урамы кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ваһапов урамы күчәре буйлап төньяк-көнбатышка таба Беренче Май урамына кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәре буйлап төньяк-көнбатышка таба Һ.Такташ тыкрыгына кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, тыкрык күчәре буйлап көньяк-көнбатышка таба Һ.Такташ урамына кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәре буйлап төньяк-көнбатышка таба Энгельс урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Энгельс урамы күчәре буйлап көньякка таба шәһәрнең көньяк-көнбатыш чигендә Казан – Оренбург автомобиль юлы һәм Энгельс урамы кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, аннары «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнбатышка таба шәһәрнең көнчыгыш чигендә Казан – Оренбург автомобиль юлы һәм Ваһапов урамы кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Баулы муниципаль районының Исергәп, Кызылъяр, Яңа Зареченский, Покровский Урустамак, Салих һәм Шалты авыл җирлекләре.

## 2 нче суд участогы

2 нче суд участогы чигенә «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көньяк-көнбатыш чигендә Казан – Оренбург автомобиль юлы һәм Энгельс урамы кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Энгельс урамы күчәре буйлап төньякка таба Һ.Такташ урамына кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Һ.Такташ урамы күчәре буйлап төньяк-көнчыгышка таба Һ.Такташ тыкрыгына кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, тыкрык

күчәре буйлап Беренче Май урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгышка борыла, так якта урнашкан йортларны кертеп, Беренче Май урамы күчәре буйлап Ваһапов урамына кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, аның күчәре буйлап шәһәрнең көнчыгыш чигендә Казан – Оренбург автомобиль юлы һәм Ваһапов урамы кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба шәһәрнең көньяк-көнбатыш чигендә Казан – Оренбург автомобиль юлы һәм Энгельс урамы кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Баулы муниципаль районының Александровка, Кырым-Сарай, Поповка, Потапово-Томбарлы, Татар Кандызы, Томбарлы һәм Удмурт Ташлысы авыл җирлекләре.